# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**№ 6** 06.12.2019 ел

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Исәнсеф авыл җирлеге составына керүче Исәнсеф торак пунктына 2020 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Исәнсеф авыл җирлеге Исәнсеф торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1 Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Исәнсеф торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертергә. Ялгыз карт гражданнар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм инвалидлар, I, II төркем инвалидлары өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә .

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- Исәнсеф авылын су белән тәэмин итүне ремонтлау һәм төзекләндерү өчен;
- Исәнсеф авылы территориясендә һәйкәлләрне ремонтлау өчен ;
- Исәнсеф авылының юлларны кышкы һәм җәйге карап тотуга;
- Исәнсеф авылының таш түшәмәсен ремонтлау өчен;
- Исәнсеф авыл клубын ремонтлау өчен төзелеш материаллары сатып алу өчен;
- Исәнсеф авылында массакүләм чаралар (Сабантуй, өлкәннәр көне, Инвалидлар көне, 9 Май, волейбол, яшьләр арасында теннис ярышлары) үткәрү өчен бүләкләр сатып алу; ;
- Исәнсеф авылы сабантуе территориясендә электр белән тәэмин итү линияләрен үткәрү өчен кабель сатып алу;
- Исәнсеф авылы урам яктырткычлары сатып алу;
- Исәнсеф авылы территориясендә үлән чабу һәм куаклар кисү;

3.Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырылган: http// muslumovo.tatarstan.ru Мөслим муниципаль районы, Татар Бүләре авылы, Дуслык урамы, 5а йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында да бар.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татар Бүләр авыл җирлеге башлыгы И.А.Салихов